КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 август г.Казань № 779

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларда Татарстан Республикасының катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 25 декабрь, 1132 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларда Татарстан Республикасының катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларда Татарстан Республикасының катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы

территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 25 декабрь, 1132 нче карары белән расланган Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларда Татарстан Республикасының катнашуына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә агросәнәгать комплексы өлкәсендәге күргәзмә һәм башка чараларны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«милли бәйрәмнәр уздыру кысаларында бәйрәм кунаклары тарафыннан дегустацияләү өчен милли ризыклар әзерләү буенча милли ризыклар күргәзмәләрен, мастер-классларны оештыру.»;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Министрлык субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.».

2. Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин